ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасының аерым закон актларына балигъ булмаганнарга автомобиль бензинын сатуны чикләүне билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2025 елның 17 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2012, № 1, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 1, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 7, № 10; 2014, № 1 – 2, № 5, № 6 (I өлеш), № 7; 2015, № 3, № 4, № 12 (I өлеш); 2016, № 5, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 85 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш); 2024, № 56 (I өлеш), № 81 (I өлеш); 2025, № 1 (I өлеш), № 18 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 49 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 2.22 статья өстәргә:

«2.22 статья. **Балигъ булмаганнарга автомобиль бензинын ваклап сатуны чикләүне үтәмәү**

Балигъ булмаганнарга автомобиль бензинын ваклап сатуны, уналты яшькә җиткән, транспорт чарасы белән идарә итү хокукына ия булган затларга транспорт чарасының ягулык багына автомобиль бензинын салганда аны сатудан тыш, чикләүне үтәмәгән өчен –

гражданнарга – өч меңнән алып биш мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга – утыз меңнән алып илле мең сумга кадәр; юридик затларга йөз меңнән алып йөз илле мең сумга кадәр административ штраф салына.»;

2) 7.1 статьяда «2.11 – 2.21» саннарын «2.11 – 2.22» саннарына алмаштырырга;

3) 8.1 статьяның 14 өлешендә «2.21,» саннарыннан соң «2.22,» саннарын өстәргә.

**2 статья**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» 2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 7 (II өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 10; 2014, № 7; 2015, № 3, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 79 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 56 (I өлеш), № 81 (I өлеш); 2025, № 18 (I өлеш), № 49 (I өлеш), аңа «2.21,» саннарыннан соң «2.22,» саннарын өстәп, үзгәреш кертергә.

**3 статья**

«Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» 2010 елның 14 октябрендәге 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш); 2013, № 10; 2015, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2022, № 83 (I өлеш); 2023, № 95 (I өлеш); 2025, № 18 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле $7^3$ статья өстәп, үзгәреш кертергә:

«$7^3$ статья. **Балигъ булмаганнарга автомобиль бензинын ваклап сатуны чикләү**

Балигъ булмаганнарга автомобиль бензинын ваклап сату, уналты яшькә җиткән, транспорт чарасы белән идарә итү хокукына ия булган затларга транспорт чарасының ягулык багына автомобиль бензинын салганда аны сатудан тыш, рөхсәт ителми.».

**4 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2025 ел, 23 июль
№ 53-ТРЗ